РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Микулинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский
район, с.Микулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 74 йорт, Азнакай
районы, Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «02» ноября 2023г.** **№ 9**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә Благодатный торак пунктында гражданнарныңүзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегендә Благодатный торак пунктында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 17 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.2 Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә Благодатный торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегенең Башкарма комитетын;
- гражданнар җыенынын үткәрү вакыты - 2023 елның 17 ноябрендә 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны – Благодатный бистэсе, Солнечная урамы, 7 йорт;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 02 ноябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авылы Башкарма *комитетында* гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышуны Микулино авылы, Советская урамы, 74 йорт адресы буенча тәэмин итәргә;

- сайлау хокукына ия булган Благодатный торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген тозергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Благодатный торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында мәгълүматны башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:
«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Благодатный торак пунктынын территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гаилә әгъзасы һәм гражданнар мобилизацияләнә».

Аерым категория гражданнар өчен:

а) 2 төркем инвалидлар,
б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,
в) күп балалы гаиләләр,

түләүләр күләме җирле референдум (гражданнар җыены) карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Благодатный бистәсендә, бакча һәм урман урамнары буенча вак таш сатып алу һәм юл чокырларын ремонтлау;
- Юлларны кардан чистарту.

| | |
|---|---|
| «РИЗА» | «КАРШЫ» |

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Микулино авылы, Советкая урамы, 74 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Глава: И.А.Тәкиулин